**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 24 мартындагы 923 номерлы карары**

**Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында**

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»гы указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне (кушымта итеп китерелә) расларга.

2. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы «Муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе вазифасына эшкә урнашучы зат тарафыннан, шулай ук муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе тарафыннан үзенең

керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләрен, шулай ук Муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Казан шәһәре Мэриясенең рәсми порталында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7167 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы карарына үзгәреш кертү турында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 30 апрелендәге 2310 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 19 мартындагы 1545 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 11 июнендәге 1460 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы “Муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе вазифасына эшкә урнашучы зат тарафыннан, шулай ук муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе тарафыннан үзенең керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләрен, шулай ук Муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Казан шәһәре Мэриясенең рәсми порталында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 25 июнендәге 1560 номерлы «Казан шәһәре Башкарма

комитетының 2013 елның 12 апрелендәге 3525 номерлы “Муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе вазифасына эшкә урнашучы зат тарафыннан, шулай ук муниципаль (бюджет, автоном) учреждение җитәкчесе тарафыннан үзенең керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләрен раслау турында”гы карарына үзгәреш кертү хакында»гы карары;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 22 августындагы 2374 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының коррупциягә каршы юнәлештәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы карары.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 24 мартындагы
923 номерлы карары белән
расланды

**Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданин түбәндәгеләрне тапшыра:

- муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәр килә торган календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынында яки сайланулы вазифа биләү урынында алынган керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәр килә торган айның беренче числосына үзе милек хокукында ия булган мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр (хисап датасына);

- муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләү өчен гражданин тарафыннан документлар тапшыру елына кадәр килә торган календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләү өчен гражданин тарафыннан документлар тапшыру аена кадәр килә торган айның беренче числосына аларның милек хокукында ия булган мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр (хисап датасына).

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы федераль закон (алга таба – 230-ФЗ номерлы федераль закон) буенча чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне тапшыра:

- 230-ФЗ номерлы федераль закон буенча чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чоры) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына үзе милек хокукында ия булган мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

- 230-ФЗ номерлы федераль закон буенча чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чоры) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына аларның милек хокукында ия булган мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 пунктлары белән каралган белешмәләр, әгәр алар федераль закон нигезендә дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәсә, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

Әлеге белешмәләр Казан шәһәре Башкарма комитетының карарлар кабул итү өлкәсендә учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган органнарына тапшырыла.

5. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданин керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында үзе тарафыннан тапшырылган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматның күрсәтелмәвен яки тулысынча күрсәтелмәвен яисә белешмәләрдә хаталар булуын ачыклаган очракта, ул әлеге Нигезләмәнең 2 пункты нигезендә белешмәләр тапшырган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләр тапшырырга хокуклы.

6. Муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында үзе тарафыннан тапшырылган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматның күрсәтелмәвен яки тулысынча күрсәтелмәвен яисә белешмәләрдә хаталар булуын ачыклаган очракта, ул

төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

7. Әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 пунктлары белән каралган белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «БК белешмәләре» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча тапшырыла. Аңа сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Муниципаль учреждение җитәкчесе объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра алмаса, ул Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль учреждение җитәкчесен вазифага билгеләү һәм вазифасыннан азат итү вәкаләтләре бирелгән вазифаи заты карамагында булган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарның үтәлешен тәэмин итү комиссиясенә тиешле гариза белән мөрәҗәгать итә.

9. Керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмаган, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшырган яки белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданин тиешле вазифага билгеләнә алмый.

10. Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмаган, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшырган яки белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр дисциплинар җаваплылыкка тартыла.